
Габдуллаҗан Мөхәммәтгариф улы Тукаев 1886 елның 13 (26) апрелендә Казан өязе Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында мулла





ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.
(“Туган авыл” Г.Тукай)





Сабыйга дүрт ай тулганда әтисе үлеп китә. Ике елдан соң әнисе Мәмдүдә Сасна Пүчинкәсе авылы мулласына кияүгә чыга. Ләкин озак та үтми, Габдулла әнисез дә кала – 1890 елның гыйнварында егерме биш яшендә әнисе үлеп китә. Дөм ятим калган бала авылдан авылга, гаиләдән гаиләгә, кулдан кулга күчеп йөри.



Баштан Габдулла бабасының зур гаиләсе белән Өчиле авылында яши. 1891 елда, ачлыкка түзалмыйча, малайны Казанга озатып, Печән базарында «саталар».

*Аны асрамага Яңа бистә һөнәрчеләре гаиләсе ала. Мөхәммәтвәли белән Газизә малайны бик кадерләп тәрбиялиләр. Ләкин авырып китүләре сәбәпле, баланы ике елдан соң тагын бабасы өенә Өчилегә кайтаралар.*

**Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!**
**Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем…**
**(Г.Тукай)**

Өчиледән Габдулланы Кырлай кешесе Сәгъди абый алып китә. Аның алдагы тормышында, язучы булып китүендә Кырлайның роле зур була.

Габдулла тугыз яшенә хәтле авылда яши. Авыл малайлары белән су буенда, балыкта. Печәне җитсә — ул да печәндә.



“Шүрәле” әкияте

үзе генә дә Кырлай

истәлегенң гүзәл бер

шигъри һәйкәле итеп

санала. .



# Казанда Тукай үзенең берсеннән- берсе матур


# шигырьләрен иҗат итә








*Тукай шагыйрь буларак тиз формалаша. Алты-җиде ел эчендә татар халкының иң яраткан, иң популяр милли шагыйренә әйләнеп китә*



***1910** елда ул үпкә чире белән интегә башлый.*

***1913** елның 2 (15) апрелендә Казанның Клячкин шифаханәсендә бөек шагыйребезнең йөрәге тибүдән туктый.*


ГАБДУЛЛА
ТУКАЙ
1886 - 1913
ع. توقاى
http://tashlar.narod.ru


ТАТАРЛАРНЫҢ
БӨЕКЛЕГЕ, ДАН
СИГЕЗ КАТ
КҮКЛӘРГӘ КИТСЕН;
МӘҢГЕ, ҺӘРВАКЫТ
БУ МИЛЛӘТНЕ
ХОДАЕМ БӘХЕТЛЕ
ИТСЕН.
абдулла Тукай

# Габдулла Тукай музейлары







# Габдулла Тукай һәйкәлләре

